| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Зеленодольский<br>муниципальный район<br>Глава<br>муниципального образования<br>«поселок городского<br>типа Нижние Вязовые»**<br>422500, пгт.Н.Вязовые, ул.Первомайская, 70 | **Татарстан Республикасы<br>Зеленодол<br>муниципаль районы<br>«Карамалы тау шэһэр<br>тибындагы поселок»<br>муниципаль берэмлекнен<br>Башлыгы**<br>422500, пгт. Н.Вязовые, ул.Первомайская, 70 |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>03.02.2022** | **КАРАР<br>№1** |

Олы Ходяш авыл җирлеге башлыгы карарларының үз көчләрен югалтуы турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында **КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип тану:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ходяш авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 21 апрелендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ходяш авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрнең үтәлешен тикшерү турында» гы карары;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ходяш авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 12 августындагы 16 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Олы Ходяш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча махсус мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт, җирле үзидарә административ бинасында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау ш.т.б., Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИнең административ бинасы).

Җирлек башлыгы Ю.М. Некрасова